



**Илүзә Гайнетдинова**



# Сәләтле бәләкәчләр



**«Сәләт» – талантлы үсмерләр һәм яшьләрне җыйнап кына калмый, ә сәләтлеләрне сабый чактан ук үстерү өчен дә көч куя. Мондый җаваплы да, кызыклы да эшләр «Бәләкәч» проекты кысаларында башкарыла. Әлеге проект үзенчәлекләрен «Идел» журналында (2016, №11) язган идек инде. Шул вакыттан соң нинди үсеш-үзгәрешләр, яңалыклар булган соң, шулар белән танышыйк.**

Бүгенге көндә «Сәләт» берләшмәсенең «Сәләт-Бәләкәч» клубы өч юнәлештә эшли. Беренчесе – «Сәләт» йортында атна саен уза торган дәресләр. Икенче юнәлеш – елына өч-дүрт тапкыр Биләрдәге «Фәнсар» фән һәм мәгариф үзәгендә үткән гаилә сменалары һәм өченчесе – «Сәләт» Форумы кысаларында эшли торган «Сәләт-Бәләкәч» клубы.

## БИЛӘРДӘ УЗГАН «СӘЛӘТ» ФОРУМЫНДА 300 САБЫЙ КАТНАШКАН

Биредә балалар ял итеп, уйнап кына калмый, «Сәләт»кә хас булганча, дәресләргә йөри. Форумда да «Сәләт» йортында килеп дәрес бирүче укытучылар үз эшләрен дәвам итте: вокал дәресләрен Ләйсән апа Әсхәтова-Арсентьева, дизайнны Гүзәл Бану, ә театр сәнгатен Альбина Садриева алып барды. «Шоу сумасшедшего профессора Николя» шоу-студиясе, «Естественно, наука!» лабораториясе, «Салават күпере» журналы быел да сабыйларны куандырды.

Сәлкипүшләрнең зур уңышларыннан берсе – тәүге тапкыр зур Биләр сәхнәсендә җыр белән чыгыш ясаулары һәркемне таң калдырды.

«Хис-кичерешләрне әйтеп бетергесез иде: монда горурлык та, ләззәт тә, эшләгән эшеңнең нәтиҗәсен күрү дә бар. Яңа уку елында яңа планнар белән янабыз. Балалар һәм дәресләр

Фотолар «Сәләт» Медиа-үзәге архивыннан алынды

санын арттырырга ниятлибез. Инглиз теле дәресләре өстәлде инде», – ди әлеге проектның җитәкчесе Алсу Салаватова.

## «ФӘНСАР» ҮЗӘГЕНДӘ – СӘЛКИПҮШЛӘР

Күптән түгел генә исә «Фәнсар» фән һәм мәгариф үзәгендә еллар белән сыналган дуслык, балаларның шат авазлары һәм чын гаилә мохите хөкем сөрде. Чөнки биредә өченче тапкыр «Сәләт-Гаилә» сменасы үтте. Аны үзләре дә кайчандыр сәлкеш булган, бүгенге көндә бәхетле әти-әни ролен башкаручы «Сәләт» ветераннары, яратып, шулай атый. «Сәләт-Бәләкәч» проекты тарафыннан оештырылган әлеге смена үзендә ун «Сәләт» гаиләсен җыйды. Смена турында әлеге проектның җитәкчесе Гүзәл Хәсәнова белән сөйләштек.

**– Гүзәл, кабаттан «Фәнсар»да җыелгансыз икән. Программа турында сөйләп үт әле.**

– «Сәләт-Гаилә» сменасы безнең өчен инде традициягә әверелде. Аның белән «Бәләкәч» клубының яңа уку елын да башлап җибәрдек. Монда утызлап кеше катнашты. Программада дәресләр, музейга бару, спорт чаралары, гаилә эстафетасы каралган иде. Смена шәп узды! Без көткәннән дә әйбәтрәк булды.

**– Синең өчен «Бәләкәч» нәрсә ул? Әлеге проект ни белән кызыклы?**

– «Бәләкәч» бик күп әти-әниләрнең, «Сәләт» ветераннарының хыялын чынга ашырды. Алар балаларын тәрбия итүгә зур игътибар бирә, сабыйны көчләп, куркытып түгел, ә кызыксындырып укытырга кирәклеген әйбәт аңлый. Бүгенге җәмгыятьтә индивидуаль караш дигән төшенчә дә бик мөһим. Әлбәттә, телебез,



мәдәниятебез сакланып калсын иде, дип тә тырышабыз.

**– Әйе, кече яшьтәге балаларга белем биргәндә бу факторлар бик мөһим шул.**

– Мәктәпкәчә яшьтәге бала бар мәгълүматны да бик тиз сеңдерә. Шуңа аларны үсендереп, илһамландырып, яңа үрләргә өндәп торырга кирәк! Шартлар туды-ру әһәмиятле. Балага бу мохиттә эмоциональ яктан да, физик яктан да уңайлы булырга тиеш.



**– Балаларга һәм аларның әти-әниләренә теләкләрең.**

– Яңа уку елы башлануга без тагын бетмәс-төкәнмәс эш дөньясына, мәшәкатьләргә чумдык. Бер фәлсәфәче галим уздырган тәҗрибә хәтергә килә. Ул савытка башта пинг-понг шарларын тутырган. Урын калмагач, чуерташ сала башлаган, аннары – ком, су... Тормышта да шулай: башта иң мөһим һәм кирәкле элементлар белән тутыру мөһим. Гаилә, балалар, сәламәтлек дисеңме... Чуерташ, су, ком кебек вак-төякләрдән башласак, мөһимрәк әйберләргә урын калмас. Зур эшләр белән тулы көннәрдә иң әһәмиятлесен аерып алып, кыйммәтләрне дөрес урнаштырсак иде.

## «БӘЛӘКӘЧ» КЛУБЫНЫҢ ҺӘР ОЧРАШУЫ – БӘЙРӘМ

Ел дәвамында яшь ярымнан алып сигез яшькәчә балалар һәр атнаның шимбә көнендә «Сәләт» йортында җыела. Биредә алар вокал, театр сәнгате, дизайн юнәлешләре буенча дәресләр ала. Эшчәнлек нәтиҗәләрен сменаның ахыргы көн концертында күрергә мөмкин иде. Сәлкипүшләрнең иң яратып башкарган җырлары «Сәләт – ул...» дип атала. «Палатка, учак һәм гитара»ны инде әти-әниләренә кушылып җырлый башлаганнар. Бу тагын бер кат буыннар алмашын ассызыклый. Дизайн дәресләрендә балалар «әйләнчек» ясарга өйрәнгәннәр. Аны җилдә сынап та карадылар.

«Бәләкәч» – рәхәт кенә түгел, уңайлы мохит тә ул. Дәрәҗәле укытучылардан дәресләр алалар, махсус биремнәр чишәләр, яңа белемнәр туплыйлар», – дип белдерде биш яшьлек Ясминәнең әнисе Айгөл Мөхәммәтҗанова.

«Бәләкәч» клубының һәр очрашуы – күңел бәйрәме ул. Шуңа да аның мөмкин кадәр озаграк дәвам итүен телибез. Сәләтнең балаларны татар теленә тартуы аеруча шатлыклы, – ди Рамилә Кәримова.

Яшь сәләтлеләр өчен балалар бакчасыннан тыш, башлангыч мәктәп яисә махсус «Сәләт» сыйныфлары булдыру планда бар. Сәләтле балалар өчен «Фәнсар» базасында лицей-интернат ачылса шәп булыр иде.

«Без балабызны бик теләп бу мәктәпкә йөртер идек. Әлеге идеянең тормышка ашуын түземсезлек белән көтәбез», – ди Айгөл Мөхәммәтҗанова.